ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 20 » март 2018 ел № 63

"Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында" 2016 елның 1 ноябрендәге 190 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. 2016 елның 1 ноябрендәге 190 номерлы карар белән расланган Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле 3.2.6 пунктын өстәп, үзгәреш кертергә:

"3.2.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3 һәм 3.2.4 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләр үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының һәм "д" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан гарызнамәләр нигезендә алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының һәм "д" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3, 3.11 пунктлары нигезендә берәр карар яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр".

2. Әлеге карар имза куелган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatar.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н. Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы Р.Р. Нотфуллин